ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

19.11.2024 с. Татарское Бурнашево 18

**Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 30 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында гражданнар арасында үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча җыен билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авылы җирлегенең Татар Борнашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә рөхсәтегез бармы:

- Татар Борнашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Татар Борнашы авылы, Совет урамы, 58 йорт адресы буенча 13.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Җыенны оештыручы итеп Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин